**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.03.2020 ел **Чирмешән авылы** **№ 94**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Чирмешән» спорт мәктәбе»**
**муниципаль бюджет учреждениесе**
**хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү**
**шартлары турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары нигезендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ::**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Нигезләмәне расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытта гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләрен башкару шарты белән кимрәк була алмый.
3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» МБУ директорына коллектив шартнамәләргә, Килешүләргә, хезмәткәрләргә түләү шартларын билгеләүче локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.
4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarsnan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин

ТР Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән
расланган
18.03.2020 ел, №94

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИРМЕШӘН» СПОРТ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТЕ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ ГИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, шул исәптән база (вазыйфаи) окладлары күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, билгели торган нормалар җыелмасы;

төп оклад – оклад, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәренең хезмәт хакы ставкасы, аның эшчәнлеге тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә, компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча;

вазыйфаи оклад - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәренең билгеле бер авырлыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын календарь ай өчен фактта эшләнгән вакытта үтәгән өчен билгеләнгән хезмәт хакы күләме, компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча;

хезмәт хакы (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәренең хезмәт хакы) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап, шул исәптән компенсация һәм стимуллаштыручы түләүләрне дә кертеп, хезмәт өчен түләү;

компенсация характерындагы түләүләр - компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр-кызыксындыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, вазыйфаларның һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - физик культура хезмәткәрләре) хезмәт хакы, вазыйфаи окладлары;

кызыксындыру характерындагы түләүләр;

компенсация характерындагы түләүләр.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яки белем алу турындагы документларны яңадан торгызуга, квалификация категориясенә ия булуга, дәүләт бүләге бирелүгә, ведомствоның аерым хөрмәтләү билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, ел саен яисә башка отпускта булган чорда, аның вакытлыча эшкә яраксызлыгы чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда хезмәт өчен түләү күләмен үзгәртүгә хокукы барлыкка килгәндә, аның хезмәтенә түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлардан соң гамәлгә ашырыла.

## II. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИРМЕШӘН» СПОРТ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫНЫҢ БАЗА ОКЛАДЛАРЫН БИЛГЕЛӘҮ

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның атамасы | Аена база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр","магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясе бирү белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | - | 11 680 | 14 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | - | 11 687 | 14 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | - | 11 693 | 14 232 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче | Структур бүлекчә | - | - | 14 301 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| квалификация дәрәҗәсе | мөдире (начальнигы): гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр белән. | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерым структур бүлекчә мөдире (начальнигы) | - | - | 14 364 |

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» МБУ медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның атамасы | Аена база окладь күләме, сум |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 11 000 |
| | Шәфкать туташы массаж буенча | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы <*> | 12 700 |
| Табиб һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 14 200 |

--------------------------------

<*> Вазифа оешмада өч һәм аннан күбрәк шәфкать туташы булганда билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның атамасы | Аена база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр","магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясе бирү белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча дежур | 9 489 | - | - |
| | Инвалидлыкның беренче төркем спортчы - инвалидын озатып йөрүче | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 9 489 | - | - |
| | Спортчы-әйдәп баручы | | | |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча инструктор | 9 489 | 11 680 | 14 200 |
| | Спорт буенча инструктор | - | 11 680 | 14 200 |
| | Спортчы-инструктор | 9 489 | | - |
| | Тренер - ат җайдагы | 9 489 | 11 680 | - |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау технигы | - | 11 680 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Күнегүләр процессы администраторы | - | 11 687 | 14 220 |
| | Адаптив физик | - | 11 687 | 14 220 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | культура буенча инструктор-методист | | | |
| | Тренер | - | 11 687 | 14 220 |
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы | - | 11 687 | 14 220 |
| | Хореограф | - | 11 687 | 14 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | - | 11 693 | 14 232 |
| | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | | | |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Аналитик (спорт төре яки төрләре төркеме буенча) | - | - | 14 301 |

III. ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ БАЗА ОКЛАДЫ
ӨЧЕН СӘГАТЬ НОРМАСЫ (ХЕЗМӘТ ХАКЫНЫҢ БАЗА СТАВКАСЫ)

1. ТР Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең эш вакытының дәвамлылыгы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2. ТР Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә эш вакыты дәвамлылыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгате нормалары) федераль һәм төбәк дәрәҗәләрендә өч яклы тармак килешүләре белән билгеләнергә мөмкин.

IV. ТР ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЧИРМЕШӘН» СПОРТ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН БАЗА ОКЛАДЫ (ХЕЗМӘТ ХАКЫНЫҢ БАЗА СТАВКАСЫ) СӘГАТЕ ӨЧЕН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ НОРМАТИВ САНЫ

1 Таблица

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЧИРМЕШӘН» СПОРТ МӘКТӘБЕ» МБУ ТРЕНЕРЛАРЫНЫҢ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА СПОРТ ӘЗЕРЛЕГЕ ЭТАПЛАРЫНДА ШӨГЫЛЬЛӘНҮЧЕНЕҢ БЕРСЕ ӨЧЕН ХЕЗМӘТ ХАКЫ НОРМАТИВЛАРЫ

(процент)

| N п/п | Спорт төре | Спорт әзерлеге этаплары | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | спорт-сәламәтләндерү | башлангыч әзерлек | | күнегүләр (спорт специализациясе) | | | | | спорт осталыгын камилләштерү | | югары спорт осталыгы |
| | | | елга кадәр | елдан артык | 1нче ел | 2нче ел | 3нче ел | 4нче ел | 5нче ел | елга кадәр | елдан артык | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | Бокс | 1,5 | 2,2 | 3,6 | 5,6 | 7,8 | 8,9 | 10,0 | 11,1 | 17,0 | 23,0 | 35,0 |
| 2. | Волейбол | 1,5 | 2,2 | 3,6 | 5,6 | 5,6 | 7,4 | 8,3 | 8,3 | 17,0 | 20,0 | 25,0 |
| 3. | Көрәш | 1,1 | 2,1 | 2,4 | 3,7 | 5,6 | 8,9 | 13,9 | 0,0 | 17,0 | 23,0 | 35,0 |
| 4. | Җиңел атлетика | 1,5 | 2,2 | 3,3 | 4,8 | 6,5 | 8,9 | 10,0 | 13,9 | 20,0 | 30,0 | 40,0 |
| 5. | Футбол | 1,5 | 2,2 | 3,0 | 3,7 | 5,6 | 6,5 | 8,9 | 12,5 | 17,0 | 20,0 | 25,0 |
| 6. | Хоккей | 1,5 | 2,4 | 3,6 | 5,6 | 8,3 | 10,0 | 10,0 | 11,1 | 17,0 | 20,0 | 25,0 |

2 Таблица

## СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА СПОРТ ӘЗЕРЛЕГЕ ЭТАПЛАРЫНДА УКУ-ТРЕНИРОВКА ЭШЕНЕҢ АТНАЛЫК РЕЖИМЫ

(сәгать )

| N п/п | Спорт төре | Спорт әзерлеге этаплары | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | спорт-сәламәтләндерү | башлангыч әзерлек | | күнегүләр (спорт специализациясе) | | | | | спорт осталыгын камилләштерү | | югары спорт осталыгы |
| | | | елга кадәр | елдан артык | 1нче ел | 2нче ел | 3нче ел | 4нче ел | 5нче ел | елга кадәр | елдан артык | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | Бокс | 4 | 6 | 9 | 12 | 14 | 16 | 18 | 20 | 24 | 28 | 32 |
| 2. | Волейбол | 4 | 6 | 9 | 12 | 12 | 16 | 18 | 18 | 24 | 28 | 32 |
| 3. | Көрәш | 4 | 6 | 6 | 8 | 12 | 16 | 20 | 0 | 24 | 27 | 36 |
| 4. | Чаңгы ярышлары | 4 | 6 | 9 | 10 | 12 | 14 | 16 | 18 | 24 | 28 | 32 |
| 5. | Футбол | 4 | 6 | 8 | 10 | 12 | 14 | 16 | 18 | 24 | 28 | 32 |
| 6. | Хоккей | 4 | 6 | 9 | 12 | 15 | 18 | 18 | 20 | 21 | 23 | 30 |

3 Таблица

## СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА СПОРТ ӘЗЕРЛЕГЕ ЭТАПЛАРЫНДА ТӨРКЕМНӘРНЕҢ НОРМАТИВ ТУЛЫЛЫГЫ

(кеше)

| N п/п | Спорт төре | Спорт әзерлеге этаплары | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | спорт-сәламәтләндерү | башлангыч әзерлек | | күнегүләр (спорт специализациясе) | | | | | спорт осталыгын камилләштерү | | югары спорт осталыгы |
| | | | елга | елдан | 1нче | 2нче | 3нче | 4нче | 5нче | елга | елдан | |

| | | | кадәр | артык | ел | ел | ел | ел | ел | кадәр | артык | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | Бокс | 15 | 15 | 14 | 12 | 10 | 10 | 10 | 10 | 6 | 5 | 3 |
| 2. | Волейбол | 15 | 15 | 14 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 10 | 10 | 8 |
| 3. | Көрәш | 20 | 16 | 14 | 12 | 12 | 10 | 8 | 0 | 6 | 6 | 4 |
| 4. | Җиңел атлетика | 15 | 15 | 15 | 14 | 12 | 10 | 10 | 8 | 4 | 4 | 2 |
| 5. | Футбол | 15 | 15 | 15 | 15 | 12 | 12 | 10 | 8 | 8 | 8 | 8 |
| 6. | Хоккей | 15 | 14 | 14 | 12 | 10 | 10 | 10 | 10 | 6 | 6 | 6 |

1. Укыту-тренировка эшенең атналык режимы максималь рәвештә һәм ул спорт төренең үзенчәлегенә, әзерлек чорына һәм бурычларына бәйле рәвештә билгеләнә. Әлеге эш режимнары белән каралган укыту-тренировка эшләренең еллык күләме, әзерлекнең укыту-тренировка этабыннан башлап, 25 процenттан кимерәккә кыскартылырга мөмкин.

2. Шөгыльләнүчеләрне яше һәм спорт әзерлеге буенча бер төркемгә берләштергәндә, аларның спорт осталыгы дәрәҗәсендә аерма ике разрядтан артмаска тиеш, ә аларның саны югары спорт осталыгы этабында 8 кешедән артмаска тиеш, спорт камилләшүе этабында - 12 кеше, укыту-тренировка эшләрендә - 16 кеше ике елдан артык шөгыльләнүчеләр өчен һәм 20 кеше - 2 елдан да кимрәк шөгыльләнүчеләр өчен, укыту - тренировка дәресләрендә куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен исәпкә алып.

3. Аерым спорт төрләрендә, төп тренердан тыш, спортчылар белән бер үк вакытта эшләү шарты белән, спортның чиктәш төрләре (акробатика, хореография һ.б.) буенча тренерлар да җәлеп ителергә мөмкин. Аларның хезмәт хакы төп тренер өчен каралган хезмәт хакы нормативының яртысыннан артмаска тиеш.

4. Ярышларда алган урын буенча югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен тренерларның хезмәт хакы нормативы ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә билгеләнә спортчы күрсәткән нәтиҗә мизгеленнән алып бер календарь ел дәвамында.

5. Югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен тренерларның хезмәт хакы нормативы ярышларда билгеләнгән урын буенча бер календарь елга билгеләнә.

6. Әгәр дә билгеләнгән урын буенча югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен хезмәт өчен түләү нормативының гамәлдә булу вакыты чыккач, спортчы башка нәтиҗә күрсәтмәсә, тренерларга хезмәт хакы нормативы әлеге Нигезләмәнең 1 һәм 4 таблицалары нигезендә билгеләнә.

7. Югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен билгеләнгән урын буенча тренерларга түләү нормативы, спортчы тарафыннан программа рәвешендә шәхси зачетта, күп төр ярышларда (многоборье), яки команда ярышларында, әгәр аларда медаль комплектлары уйнатылса, күрсәтелгән һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) бер иң яхшы нәтиҗә өчен процент суммасыннан билгеләнә.

8. Спортның аерым төрләрендә (шәхси һәм команда) югары квалификацияле спортчылар әзерләгәндә җәлеп ителә торган спортның чиктәш төрләре (акробатика, хореография һ.б.) буенча тренерлар өчен югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен билгеләнгән урын нигезендә тренерларның хезмәт хакы нормативлары, әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 5нче

таблицаларында билгеләнгән спортчыларның укыту-тренировка эшенең атналык режимыннан эшләнгән вакытка пропорциональ күләмендә төп тренерларга кебек үк шартларда билгеләнә.

9. Рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында ирешелгән нәтиҗәләр өчен спортчы-инструктор һәм спортчыларның хезмәт хакы нормативы, билгеләнгән урын буенча, ярышлар беркетмәсеннән спортчы-инструкторлар, спортчылар күрсәткән нәтиҗә вакытыннан алып бер календарь ел дәвамында билгеләнә.

10. Рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында ирешкән нәтиҗәләр өчен спортчы-инструктор һәм спортчыларның хезмәт хакы нормативы билгеләнгән урын буенча бер календарь елга билгеләнә.

11. Рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында ирешкән нәтиҗәләр өчен билгеләнгән урын буенча спортчы-инструктор һәм спортчыларның хезмәт хакы нормативы, спортчы тарафыннан программа рәвешендә шәхси зачетта, күп төр ярышларда (многоборье), яки команда ярышларында, әгәр аларда медаль комплектлары уйнатылса, күрсәтелгән һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчы-инструкторның, спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) бер иң яхшы нәтиҗә өчен процент суммасыннан билгеләнә.

12. Россия Федерациясе спорт министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән бөтенроссия ярышлары исемлеге, аның буенча ярышларда уңышлы чыгыш ясаган югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларны бүләклиләр, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

## V. ТР ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИРМЕШӘН» СПОРТ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ТӘРТИБЕ

1. Тренерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

кайда:

$O_d$ - тренерларның окладлары;

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$N_i$ - спорт төрләре буенча спорт әзерлеге этапларында бер шөгыльләнүче өчен тренерларга хезмәт өчен түләү нормативлары;

K - күчеш чорына компенсация коэффициенты, ул күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы санын спорт-сәламәтләндерү этабында һәм башлангыч әзерлек этабында норматив мәгънәгә җиткерүне тәэмин итә;

n - укучылар саны.

2. Билгеләнгән урын буенча югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларның оклады формула буенча исәпләнә:

кайда:

$O_v$ - билгеләнгән урын буенча югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларның оклады;

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура хезмәткәрләренең база оклады күләме;

 - билгеләнгән урын буенча югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларның хезмәт хакы нормативлары;

n - укучылар саны.

3. Медицина хезмәткәрләренең, физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

кайда:

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган хезмәткәрләренең база окладты күләме;

S - факттагы ставкалар саны.

## VI. КЫЗЫКСЫНДЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР

1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

1.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләр үз эченә ала:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

эшнең югары нәтиҗәләре өчен түләүләр;

югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр;

спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр;

дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;

премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

4.6. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_{sr},$$

кайда:

$B_s$ - профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, ул 13 таблицада китерелгән.

2. Спорт резервын әзерләү оешмаларының медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләмнәре һәм тәртибе.

2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тотучы белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

кайда:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 4 таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

4 Таблица

КВАЛИФИКАЦИЯ КАТЕГОРИЯСЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләү, процентлар күләме |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиб һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

2.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр аерым учреждениеләрдә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

кайда:

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме 16,2 процент тәшкил итә.

2.3. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфаларда конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләр исемлеге һәр оешма тарафыннан сайлап куелган профсоюз органы яки хезмәткәр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган белән килештереп раслана.

2.4. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

кайда:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Берлеге составында автоном республикалар дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Берлеге, Совет Социалистик Республикалары Берлеге составында союз республикалары дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

2.5. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләргә, алар булган өчен түләү хезмәткәрнең теләге буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

2.6. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм формула буенча исәпләнә:

$B_s = O_d \times D_{sr}$,

кайда:

$B_s$ - профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, ул 13 таблицада китерелгән.

5 Таблица

ПРОФИЛЬ БУЕНЧА ЭШ СТАЖЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

2.7. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкәннән соң, стажны раслаучы документлар оешмада булса, яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

2.8. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

кайда:

$B_{sr}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладаы;

$D_{sr}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме, ул 6 таблицада китерелгән.

6 Таблица

ХЕЗМӘТ ИНТЕНСИВЛЫГЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ КҮЛӘМЕ

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмәләр диапазоны, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | икенче | 1,5 |
| | өченче | 3,0 |
| | дүртенче | 4,5 |
| | бишенче | 10,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Табиблар һәм провизорлар | беренче - икенче | 3,0 |

3. Спорт резервын әзерләү оешмаларының физик культура хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренә, аларда гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта, квалификация категориясе гамәлдә булу срогы чикләрендә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \text{ x } D_{kk},$$

кайда:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 7 таблицада китерелгән.

7 Таблица

ФИЗИК КУЛЬТУРА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ
КВАЛИФИКАЦИЯ КАТЕГОРИЯСЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР
КҮЛӘМЕ

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 (11,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 6,0 (13,0 <*>) |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 6,0 (11,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 8,5 (13,0 <*>) |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 7,5 (12,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 (15,5 <*>) |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 8,5 |
| | югары квалификация категориясе | 12,5 |

--------------------------------

<*> Физкультура спорт оешмаларының тренеры, инструктор-методисты (шул исәптән өлкән)

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

3.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

вазыйфаи оклад буенча тарификацияләнүче хезмәткәрләр өчен:

оклад (хезмәт хакы ставкасы) буенча тарифлаштырыла торган хезмәткәрләр өчен:

кайда:

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$D_{sd}$ - олимпия резервының махсуслаштырылган оешмаларында (бүлекләрендә) эшчәнлек спецификасы өчен өстәмә түләү күләме, 7 процентка тигез кабул ителә;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$O_b$ - хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

 - кулланучыларның билгеле бер категорияләре белән спорт резервын әзерләү оешмаларының физик культура хезмәткәрләренең эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$ - спорт резервын әзерләү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакының әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә билгеләнгән база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$N_i$ - спорт төрләре буенча спорт әзерлеге этапларында бер шөгыльләнүче өчен тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәр) спорт резервын әзерләү оешмаларында хезмәт хакы нормативлары;

m - кулланучылар саны, алар белән эшләү өчен эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр билгеләү каралган.

3.3. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфаларда конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлекләренә өстәмәләр билгеләнә торган физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге һәр оешма тарафыннан сайлап куелган профсоюз органы яки хезмәткәр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган белән килештереп раслана.

3.4. Ярышларда алган урыны буенча югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгыш ясаганнары һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{vrr} = O_d \times D_{vrr},$$

кайда:

$B_{vrr}$ - эшнең югары нәтиҗәләре өчен түләүләр;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{vrr}$ - эшнең югары нәтиҗәләре өчен өстәмә түләү күләме, ул 8 таблицада китерелгән.

3.5. Ярышларда алган урын буенча югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә спортчы күрсәткән нәтиҗә вакытыннан алып бер календарь ел дәвамында билгеләнә.

5.6. Ярышларда алган урын буенча югары эш нәтиҗәләре өчен түләү срогы бер календарь елга билгеләнә.

5.7. Ярышларда алган урын буенча югары нәтиҗәләр өчен өстәмә күләме спортчы, спортчы-инструктор тарафыннан программа рәвешендә шәхси зачетта, күп төр ярышларда (многоборье), яки команда ярышларында, әгәр аларда медаль комплектлары уйнатылса, күрсәтелгән һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) бер иң яхшы нәтиҗә өчен процент суммасыннан билгеләнә.

8 Таблица

ЭШНЕҢ ЮГАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ
(процент)

| Ярышларның дәрәҗәсе | Яулап алынган урын | Өстәмә түләү күләме | |
|---|---|---|---|
| | | олимпия спорт төрләре, олимпия дисциплиналары | олимпиянеке булмаган спорт төрләре, олимпиянеке булмаган дисциплиналар |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Олимпия уеннары | 1 | 500,0 | - |
| | 2 | 375,0 | - |
| | 3 | 250,0 | - |
| | 4 | 200,0 | - |
| | 5 | 187,5 | - |
| | 6 | 125,0 | - |
| | катнашу | 62,5 | - |
| Дөнья чемпионаты | 1 | 150,0 | 105,0 |
| | 2 | 140,0 | 100,0 |
| | 3 | 130,0 | 95,0 |
| | 4 | 120,0 | 90,0 |
| | 5 | 110,0 | 85,0 |
| | 6 | 100,0 | 70,0 |
| Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 | 140,0 | 100,0 |
| | 2 | 130,0 | 90,0 |
| | 3 | 120,0 | 85,0 |
| | 4 | 110,0 | 75,0 |
| | 5 | 100,0 | 70,0 |
| | 6 | 90,0 | 65,0 |
| Европа кубогы, дөнья беренчелеге | 1 | 120,0 | 85,0 |
| | 2 | 110,0 | 75,0 |
| | 3 | 100,0 | 70,0 |
| | 4 | 90,0 | 65,0 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 120,0 | 85,0 |
| | 2 | 110,0 | 75,0 |
| | 3 | 100,0 | 70,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4 | 90,0 | 65,0 |
| Россия чемпионаты, Европа беренчелеге | 1 | 100,0 | 70,0 |
| | 2 | 90,0 | 65,0 |
| | 3 | 80,0 | 55,0 |
| | 4 | 70,0 | 50,0 |
| Россия кубогы, Россия беренчелеге | 1 | 80,0 | 55,0 |
| | 2 | 70,0 | 45,0 |
| | 3 | 60,0 | 40,0 |
| | 4 | 50,0 | 35,0 |
| Бөтенроссия универсиадасы | 1 | 35,0 | 17,5 |
| | 2 | 30,0 | 15,0 |
| | 3 | 25,0 | 12,5 |
| | 4 | 20,0 | 10,0 |

3.8. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләүләр беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменең беренче квалификация дәрәҗәсендәге хезмәткәрләренә һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре буенча хезмәткәрләргә (спортчылар-инструкторлардан, спортсменнардан тыш) рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгыш ясаганнары һәм спортчылар ирешкән нәтиҗәләре өчен бирелә, хезмәткәр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{vytp} = O_d \times D_{vytp},$$

кайда:

$B_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен өстәмә күләме 9 таблицада китерелгән.

3.9. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр спортчы күрсәткән нәтиҗәдән чыгып ярышлар беркетмәсеннән бер календарь ел дәвамында билгеләнә.

3.10. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләү срогы бер календарь елга билгеләнә.

3.11. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен өстәмә күләме спортчы, спортчы-инструктор тарафыннан программа рәвешендә шәхси зачетта, күп төр ярышларда (многоборье), яки команда ярышларында, әгәр аларда медаль комплектлары уйнатылса, күрсәтелгән һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) бер иң яхшы нәтиҗә өчен процент суммасыннан билгеләнә.

9 Таблица

ЮГАРЫ СЫЙФАТЛЫ УКЫТУ-ТРЕНИРОВКА ПРОЦЕССЫН ТӘЭМИН ИТКӘН ӨЧЕН ӨСТӘМӘ КҮЛӘМЕ

(процент)

| Квалификация дәрәҗәсе | Ярышларның дәрәҗәсе | Яулап алынган урын | Өстәмә түләү күләме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | олимпия спорт төрләре, олимпия дисциплиналары | олимпиянеке булмаган спорт төрләре, олимпиянеке булмаган дисциплиналар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 2,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 2,5 | 1,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 1,5 | 1,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 1,5 | 1,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 1,5 | 1,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 1,0 | 1,0 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 3,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 3,0 | 2,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 2,5 | 2,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 2,5 | 2,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 2,0 | 1,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 2,0 | 1,5 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 2,5 | 2,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 1,5 | 1,5 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 3 | 3 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 3,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 3,5 | 3,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 3,0 | 2,5 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 2,5 | 1,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 2,5 | 1,5 |
| | дөнья һәм Европа | 1 - 6 | 2,5 | 2,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | беренчелеге | | | |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 2,5 | 2,0 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,0 | 2,0 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 4,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 3,5 | 3,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 2,5 | 2,5 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,0 | 2,0 |
| Өченче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 5,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 5,0 | 4,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 4,0 | 3,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 3,0 | 3,0 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,5 | 2,5 |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 6,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 6,0 | 5,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 5,0 | 4,5 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 4,5 | 4,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 3,5 | 3,5 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 7,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 7,5 | 6,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 6,0 | 4,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 5,5 | 5,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 4,5 | 4,5 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 4,0 | 4,0 |
| Дүртенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 12,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 12,5 | 7,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 7,5 | 6,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 7,5 | 6,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 7,0 | 7,0 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 6,0 | 6,0 |
| | спорт мәктәпләре арасында яшьләр, укучылар спартакиадасы, Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 5,0 | 5,0 |

3.12. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$B_s = O_d \times D_s,$$

кайда:

$B_s$ - профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ - хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме 10 таблицада китерелгән.

10 Таблица

ПРОФИЛЬ БУЕНЧА ЭШ СТАЖЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (1 төркем) | беренче - икенче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (2 төркем) | беренче - өченче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 (3,0 <*>) |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 (4,5 <*>) |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 (5,5 <*>) |
| | | 15 елдан артык | 5,5 (6,5 <*>) |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (3 төркем) | беренче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |

--------------------------------

<*> Физкультура-спорт оешмаларының тренеры, инструктор-методисты (шул исәптән өлкән)

3.13. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкәннән соң, стажны раслаучы документлар оешмада булса, яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

4. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр төп эш урыны буенча һәм төп вазыйфасы буенча спорт резервын әзерләү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, физик культура хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт эчендә хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләү күләменә йогынты ясый торган төп критерий - оешма хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

4.1. Хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары оешма җитәкчесе тарафыннан оешма белән идарә итүнең дәүләт-иҗтимагый характерын тәэмин итүче орган белән килешенеп раслана. Хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү

критерийларының мәгънәләре һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары оешма алдында куелган бурычлар нигезендә ел саен билгеләнә.

4.2. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрне гамәлгә ашыру күләме, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнә.

4.3. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

кайда:

- башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

- j-хезмәткәр буенча эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең тиешле (отнормированный) i-критерие;

- эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i - критерийның чагыштырма авырлык коэффициенты;

n - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре саны.

4.4. Предельный совокупный размер весовых коэффициентов по критериям эффективности деятельности работников представлен в таблицах 11- 13. Хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме 11-13 нче таблицаларда күрсәтелгән.

11 Таблица

МӘГАРИФ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ БУЕНЧА АВЫРЛЫК КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЧИК ҖЫЕЛМА КҮЛӘМЕ

| N п/п | Вазыйфаның атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 1.1. | Физик культура буенча инструктор | беренче | 45 |
| 1.2. | Педагог-оештыручы | икенче | 50 |
| 1.3. | Педагог-психолог | өченче | 55 |

12 Таблица

МЕДИЦИНА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ БУЕНЧА ҮЛЧӘҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЧИК ҖЫЕЛМА КҮЛӘМЕ

| N п/п | Вазыйфаның атамасы | Авырлык |
|---|---|---|

| | | коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Шәфкать туташы | 40 |
| 1.2. | Шәфкать туташы массаж буенча | 40 |
| Дүртенче квалификация төркеме | | |
| 1.3. | Фельдшер | 45 |
| Бишенче квалификация төркеме | | |
| 1.4. | Өлкән шәфкать туташы | 50 |
| 2. Табиб һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |

13 Таблица

## ФИЗИК КУЛЬТУРА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ БУЕНЧА ҮЛЧӘҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЧИК ҖЫЕЛМА КҮЛӘМЕ

| N п/п | Вазыйфаның атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (1 төркем) | | | |
| 1.1. | Спорт залы буенча дежур | беренче | 5 |
| 1.2. | Беренче төркем инвалидлыктагы спортчы-инвалидны озатып йөрүче | беренче | 5 |
| 1.3. | Спортчы | икенче | 15 |
| 1.4. | Спортчы-әйдәп баручы | икенче | 15 |
| 2. Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |
| 2.1. | Спорт буенча инструктор | беренче | 45 |
| 2.2. | Адаптив физик культура буенча инструктор | беренче | 45 |
| 2.3. | Спортчы-инструктор | беренче | 45 |
| 2.4. | Тренер - ат җайдагы | беренче | 45 |
| 2.5. | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | беренче | 45 |
| 2.6. | Күнегүләр процессы администраторы | икенче | 50 |
| 2.7 | Тренер | икенче | 50 |
| 2.8. | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист | икенче | 50 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.9. | Адаптив физик культура һәм спорт буенча тренер-укытучы | икенче | 50 |
| 2.10. | Хореограф | икенче | 50 |
| 2.11. | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | өченче | 55 |
| 2.12. | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | өченче | 55 |
| 3. Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |
| 3.1. | Аналитик (спорт төре яки төрләре төркеме буенча) | беренче | 60 |

## VII. КОМПЕНСАЦИЯ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР

1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

авыл җирлегендә эшләгән өчен белгечләргә түләү;

физик яки акыл үсешендә кимчелекләре булган затлар һәм инвалидлар белән эшләгән өчен түләү;

зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләүдә мәшгуль хезмәткәрләргә түләү;

нормальдән читләшкән шартлардагы эш өчен түләүләр (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, йөкләмәдән тыш (сверхурочной) эштә, төнлә эшләү һәм нормальдән читләшкән башка шартлардагы эшләрне башкарганда).

2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә.

3. Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче физик культура хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналының һәм табиб һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

кайда:

$B_{sm}$ - авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү;

$D_{sm}$ - авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү күләме, 1 388,5 сум тәшкил итә;

S - факттагы ставкалар саны.

## VIII. ОЕШМА ҖИТӘКЧЕСЕ, ОЕШМА ҖИТӘКЧЕСЕ УРЫНБАСАРЫ,

БАШ БУХГАЛТЕРНЫҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫН БИЛГЕЛӘҮ
ТӘРТИБЕ

1. Оешма җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладлардан, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән тора.

2. Спорт резервын әзерләүне оештыру җитәкчесе вазыйфаи окладны гамәлгә куючы тарафыннан елга бер тапкыр агымдагы елның 1 сентябренә яки оешма барлыкка килгән көнгә, хезмәткә түләү буенча төркемнәргә карап билгеләнә һәм формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

кайда:

$O_d$ - оешма җитәкчесенең вазыйфаи окладны;

$O_b$ - җитәкченең база окладны күләме;

S - факттагы ставкалар саны.

Җитәкченең хезмәт хакы буенча төркем шөгыльләнүчеләр санына карап билгеләнә.

3. Оешма җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының вазыйфаи окладлары әлеге оешма җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

4. Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең база һәм вазыйфаи окладлары күләме 14нче таблицада күрсәтелгән.

5. Оешманы гамәлгә куючы оешма җитәкчесенә, эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүне билгели ала.

Җитәкчегә кызыксындыру характерындагы түләүләр 14нче таблицада күрсәтелгән.

Оешма җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен башкарыла ала.

6. Оешма җитәкчесе җитәкче урынбасарларына, оешманың баш хисапчысына, аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүне билгели ала. Башкарылучы эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга ай саен, квартал саен, бер ел эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр башкарылырга мөмкин. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе оешма җитәкчесе башкарган эшләренең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 процентына кадәр күләмдә билгеләнә.

14 Таблица

ҖИТӘКЧЕЛӘРНЕҢ БАШКАРЫЛА ТОРГАН ЭШЛӘРЕНЕҢ СЫЙФАТЫ ӨЧЕН БАЗА ОКЛАДЛАРЫ ҺӘМ КЫЗЫКСЫНДЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР КҮЛӘМЕ

| Җитәкченең хезмәт хакы буенча төркем | Күләмле күрсәткечнең әһәмияте (шөгыльләнүчеләр саны, дәүләт биреме нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә), кеше <*> | База оклады, сум | Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 0 - 200 | 18 000 | 1 000 |
| 2 | 201 - 400 | 20 000 | 2 000 |
| 3 | 401 - 700 | 24 000 | 2 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 25 000 | 3 000 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 28 000 | 4 000 |
| 6 | 1 801 и выше | 30 000 | 5 000 |

--------------------------------

<*> Спорт резервын әзерләүне оешмасы укучыларының контингенты (спорт-адаптив мәктәп) 3 коэффициенты белән исәпкә алына